РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«25» июнь 2021 ел г. Альметьевск № 24

Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының «Капиталь төзелеш объектларын төзүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 16 гыйнварындагы 01 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесен бетерү турында» Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 13 маендагы 632 номерлы карары нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының «Капиталь төзелеш объектларын төзүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 16 гыйнварындагы 01 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косаревка йөкләргә.

Шәһәр
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Р. Исхаков

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ